Татарстан Республикасы

# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасы Чистай районы һәм Чистай шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 7 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Чистай районы һәм Чистай шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 1 августы
№ 47-ТРЗ

“Татарстан Республикасы Чистай
районы һәм Чистай шәһәре буенча
Татарстан Республикасы җәмәгать
судьяларының суд участоклары чикләре
турында” Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Татарстан Республикасы Чистай районы һәм Чистай шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

**1 нче суд участогы**

1 нче суд участогы чигенә “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Фрунзе һәм Карл Маркс урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә Фрунзе урамындагы 157 нче йорт янында урнашкан ноктадан алып төньякка таба Фрунзе урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Ленин урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Ленин урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Бутлеров урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба, Ленин урамының күчәр сызыгы дәвамы булып, шул ук юнәлештә Кама елгасының сул ярына кадәр бара, аннары Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча Чистай муниципаль районының сусаклагыч акваториясе буенча узучы төньяк чигенә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көнчыгышка таба Чистай муниципаль районы чиге буйлап (Кама елгасының сул ярының яр сызыгы буенча) “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге, Булдырь авыл җирлеге һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан тоташу ноктасына кадәр уза, алга таба көньяк юнәлештә “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең көнчыгыш чиге буйлап Чистай – Александровка – Түбән Кама автомобиль юлы белән кисешкәнче бара, аннары суд участогы чиге уңга борыла һәм көнбатышка таба әлеге автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап әйләнгечле автомобиль юлы һәм Кулясов урамының күчәр сызыклары белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньякка таба әйләнгечле автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Көньяк урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба Көньяк урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Карл Маркс урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Карл Маркс урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Фрунзе урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Чистай муниципаль районының Олы Талкыш, Совхозно-Галактионовский һәм Чытырчы авыл җирлекләре.

**2 нче суд участогы**

2 нче суд участогы чигенә "Чистай шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Карл Маркс һәм Бутлеров урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Карл Маркс урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Маринин урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Маринин урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Вахитов урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Вахитов урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Шәмсетдинов урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк юнәлештә Шәмсетдинов урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Новосельская урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Новосельская урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Пушкин урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньякка таба Пушкин урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Вәлиев урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көнбатышка таба Вәлиев урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Җиңүнең 40 еллыгы урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк юнәлештә Җиңүнең 40 еллыгы урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Чистай – Аксубай – Нурлат автомобиль юлына кадәр бара, алга таба шул ук юнәлештә автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап "Чистай шәһәре" муниципаль берәмлегенең көньяк чигенә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көнбатыш юнәлештә "Чистай шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге буйлап Левитан урамындагы исемсез инеш аша автомобиль юлы күперенә кадәр бара, алга таба суд участогы чиге төньяк юнәлештә чокыр төбе буйлап (инеш агымы буенча аска таба), Левитан, Чапаев, Пролетарская һәм Демьян Бедный урамнарында уң якта урнашкан йортларны кертеп, Маркин һәм Бутлеров урамнары тоташкан җирдә урнашкан автомобиль юлы күперенә кадәр уза, алга таба көнчыгышка таба Бутлеров урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Карл Маркс урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Чистай муниципаль районының Югары Кондрата, Кече Талкыш, Мөслим, Нарат-Елга, Түбән Кондрата, Татар Баганалысы, Татар Ялтаны һәм Чуаш Ялтаны авыл җирлекләре.

**3 нче суд участогы**

3 нче суд участогы чигенә "Чистай шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Энгельс һәм Маркин урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнбатышка

таба Энгельс урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Казан – Оренбург – Чистай автомобиль юлына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Казан – Оренбург – Чистай автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең көнбатыш чигенә кадәр уза, алга таба көньяк юнәлештә “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге чиге буйлап Левитан урамында Луч поселогының төньяк-көнчыгыш кырые янында урнашкан исемсез инеш аша автомобиль юлы күперенә кадәр бара, аннары суд участогы чиге сулга борыла һәм төньяк юнәлештә чокыр төбе буйлап (инеш агымы буенча аска таба), Чокырлы, Маяковский, Виктор Ногин, Николай Ногин, Кузнечная һәм Чехов урамнарында сул якта урнашкан йортларны кертеп, Маркин һәм Бутлеров урамнары тоташкан җирдә урнашкан автомобиль юлы күперенә кадәр уза, алга таба көнбатышка таба Маркин урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Энгельс урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

3 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Чистай муниципаль районының Гаделша, Булдырь, Данауровка, Кубас, Яуширмә һәм Чистай авыл җирлекләре.

**4 нче суд участогы**

4 нче суд участогы чигенә “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Карл Маркс һәм Бутлеров урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Карл Маркс урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Маринин урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Маринин урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Вахитов урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Вахитов урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Шәмсетдинов урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк юнәлештә Шәмсетдинов урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Новосельская урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Новосельская урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Пушкин урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньякка таба Пушкин урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Вәлиев урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көнбатышка таба Вәлиев урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Җиңүнең 40 еллыгы урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк юнәлештә Җиңүнең 40 еллыгы урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Чистай – Аксубай – Нурлат автомобиль юлына кадәр бара, алга таба шул ук юнәлештә автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең көньяк чигенә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге

чиге буйлап Чистай – Александровка – Түбән Кама автомобиль юлы белән кисешкәнче уза, алга таба суд участогы чиге көнбатышка таба автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап әйләнгечле автомобиль юлы һәм Кулясов урамының күчәр сызыклары белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньякка таба әйләнгечле автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Көньяк урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба Көньяк урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Карл Маркс урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Карл Маркс урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Фрунзе урамының күчәр сызыгы белән Фрунзе урамындагы 157 нче йорт янында кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба төньякка таба Фрунзе урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Ленин урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба Ленин урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Бутлеров урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба, Ленин урамының күчәр сызыгы дәвамы булып, шул ук юнәлештә Кама елгасының сул ярына кадәр уза һәм алга таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча Чистай муниципаль районының сусаклагыч акваториясе буенча узучы төньяк чигенә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көнбатышка таба Чистай муниципаль районы чиге буйлап "Чистай шәһәре" муниципаль берәмлеге, Данауровка авыл җирлеге һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан тоташу ноктасына кадәр уза, алга таба көньяк юнәлештә "Чистай шәһәре" муниципаль берәмлегенең көнбатыш чиге буйлап Казан – Оренбург – Чистай автомобиль юлы белән кисешкәнче бара, аннары суд участогы чиге сулга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Энгельс урамына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Энгельс урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Маркин урамы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көнчыгышка таба Маркин һәм Бутлеров урамнарының күчәр сызыклары буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Карл Маркс урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

4 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Чистай муниципаль районының Исләй, Каргалы, Иске Роман, Татар Сарсазы, Татар Талкышы һәм Чистай Выселкасы авыл җирлекләре.